

БАШКАЛА СУЛЫШЫ

Казанда узган елга нәтиҗә чыгардылар

> 2

БОЗ БӘЛАСЕ

Кышның куркыныч чагы җитте

> 2

ИҖАТ БӘЙРӘМЕ

Халыкара туган тел көнендә әдәби бәйгегә нәтиҗәләр ясалды

> 3

ҮЛЕМ ЮЛЫНДА

Фән урынына наркотикны сайлаган егетнең киләчәге төрмәдә узачак

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 26 (28799) | Сишәмбе | 22 февраль | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

САКЛАУЧЫ ДА, ЯКЛАУЧЫ ДА СЕЗ!

Бәйрәм уңаеннан

Ватанпәрвәрлек гаилә тәрбиясеннән, әти-әнигә хөрмәт хисеннән башлана. Нурлат шәһәрендә яшәүче Ирина Алексашкина әнә шул фикердә. Берьюлы ике улын хәрби хезмәткә озатып көтеп алган әни кеше уллары белән горурланып туя алмый. Игезәк уллары Михаил белән Григорий Севастополь шәһәрендә һава-космик көчләр гаскәрендә хезмәт итеп кайткан.

Михаил һәм Григорий Алексашкиннар хәрби хезмәтне әле дә сагынып искә алалар.

«Улларыбыз кечкенәдән мөстәкыйль булдылар. Эшне кызныкы-малайныкына бүлмәделәр, безгә һәрчак ярдәм иттеләр. 9 сыйныфтан соң техникумга укырга кергәч тә, армиягә барырга карар кылдылар. Армиядән соң тагын да ныгып, чын ир-ат булып кайттылар. Хәрби хезмәтне әле дә сагынып искә алалар. Прапорщиклары белән гел аралашып, элемтәдә торалар», – дип сөйләде Ирина ханым «ВТ» хәбәрчесенә.

Ватанны саклаучылар бәйрәме якынлашкан көннәрдә мондый хатирәләр аеруча яңара. Буй җиткән лачындай улыңның ил сагына китүе бер горурлык булса, аның исән-сау хезмәт итеп кайтуы – икеләтә куаныч. Киткәннәрнең хәлен исә көткәннәр генә белә. Арча районының Күпербаш авылында яшәүче Лилия Мөхәммәтҗанованың улы Ранил дә бу көннәрдә Ватан сагында. Егет Ростов-Дон шәһәрендә хезмәт итә. «Үз малаең армиягә киткәч, хәбәрләрнең яхшысы да, начары да колакка керә икән ул. Начарларын йөрәккә якын алмаска тырышабыз. Барысы да яхшы була күрсен. Улыбыз программист белгечлеге буенча Арча педагогия көллиятен тәмамлады. Дипломын яклауга ук үз теләге белән армиягә китте. Дипломын әтисе белән барып алдык. Җитмәсә, ул, көнне икебезнең дә туган көн иде. Улыбыз безгә шундый бүләк ясады», – дип искә алды ул көннәрне Лилия ханым.

Ашаган белми, тураган белә дигәндәй, Ватанны саклау төшенчәсенең асылын да бу җаваплы эшне үз җилкәсендә башкарып караган кеше генә төптән күзаллый. Күптән түгел армия сафларында хезмәт итеп кайткан баянчы, музыкант Ильяс Фәрхуллин да әнә шундый батырлар сафында. Мәскәү өлкәсендә Хәрби диңгез флоты карамагындагы элемтә гаскәрендә хезмәт иткән ул. «Армия – чын ир-егет булып кайтырга, алдагы тормышка план корырга, үз-үзеңне аңларга өйрәтә торган җирләрнең берсе. Хәрби хезмәттән күзем ачылып кайтты дисәм, ялгыш булмас. Киткәнче дә үз фикерем бар иде. Үз тормышың өчен үзең җаваплы дигән фикер канга сеңде», – ди Ильяс.

Үз героебыз кирәк

Арча һәм Әтнә районнары буенча хәрби комиссар Алмаз Борһанов Ватанны саклау ир-атның гына түгел, хатын-кызның да бурычы дип саный.

– Ни өчен бу урында гүзәл затларны да телгә алдыммы? Хатын-кыз да хезмәт хакы ала, аннан салым тотыла, шуның 1–2 проценты оборона тармагына китә. Димәк, илне саклауга гүзәл затлар да үз өлешен кертә, – ди ул.

Алмаз Борһанов яшьләр арасында ватанпәрвәрлек тәрбияләү эшен дә нәкъ менә шушы Ватанны саклауның һәркайсыбызның бурычы икәнлеген аңлатудан башлау яклы:

– Туган җир һәркемгә кадерле. Аны һәрберебез сакларга тиеш. Бүген яшьләр аны аңлап кына бетерми. Ватанпәрвәрлек хисе тәрбияләү массакүләм мәгълүмат чаралары, интернет аша да алып барылырга тиеш. Хәзерге вакытта безнең балалар ни ир кеше, ни хатын-кыз булмаган сәер затларга мөкиббән китеп, аларның җырларын тыңлап мәш килә. Ә бит аларга үрнәк итеп куярлык күпме геройларыбыз бар. Бөек Ватан сугышы ветераннары, әфган сугышында катнашкан батырлар дисеңме. Әнә шуларны күтәреп, аларны үрнәк итеп куярга кирәк.

Арабызда чын ир-атларның булуына да сөенә ул. Бүген 150дән артык Арча егете Ватан алдында изге бурычын үти. Алар барысы да армиягә үз теләге белән киткән. «Үз теләге булмаган кешене армиягә җибәрмәскә тырышам. Ник дигәндә, ул командирга да, минем башка да тимер таяк кына булачак», – ди Алмаз Борһанов.

Ахыры 4 нче биттә >

КҮГЕБЕЗ АЯЗ БУЛСЫН!

Татарстан Республикасы Премьер-министры Алексей ПЕСОШИНның 23 февраль – Ватанны саклаучылар көне белән КОТЛАВЫ

Илебез 23 февральдә Ватанны саклаучылар көнен билгеләп үтә. Чын мәгънәсендә бөтен халык бәйрәме бу. Ул сугыш елларында Ватаныбызның хөрлеге өчен көрәшкән, кайнар нокталарда ил бәйсезлеген саклаган фидакарьләрнең, бүген Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында илебез чикләрен саклаучыларның һәркайсына иксез-чиксез ихтирам билгесе булып тора.

Хәрби бурычын намус белән үтәп, яшь буында ватанпәрвәрлек рухын, Россиянең данлыклы хәрби традицияләренә ихтирам хисен тәрбияләүче армия һәм флот ветераннарына аерым рәхмәт сүзләре белдерәсем килә.

Бүген без, элеккечә, яңаны булдыру юлындагы тыныч тормышыбызның ышанычлы саклануына инанабыз. Россия Кораллы Көчләренең кадрлар составы ныгытыла, офицерлар һәм солдатларның профессиональ күнекмәләре үстерелә, хәрби подразделениеләрнең матди-техник базасы яхшыртыла.

Татарстан Республикасы да илнең оборона куәтен ныгытуга үзеннән саллы өлеш кертеп килә. Илнең хәрби-сәнәгать комплексына керүче предприятиеләребезнең зур мөмкинлекләре, армия һәм флотны заманча корал һәм техника белән тәэмин итү өчен, иң катлаулы оборона заказларын үтәүгә юл ача.

Бәйрәм белән сезне, Ватанны саклаучылар! Сезгә һәм гаиләләрегезгә нык сәламәтлек, иминлек һәм иртәгәсе көнгә ышаныч телим! Күк йөзебез һәрвакыт аяз һәм тыныч булсын!

Шәхси йорт алучылар арткан

Росреестрның Татарстандагы идарәсе гыйнвар аенда торак йорт сатып алу буенча 700гә якын ипотека килешүе теркәгән. Шулай ук җир кишәрлекләрен ипотекага алучылар да арткан. Елның беренче аенда 2,4 мең кишәрлек теркәлгән.

Росреестр идарәсе җитәкчесе урынбасары Лилия Борһанова әйтүенчә, узган елның гыйнварында ипотекага җир кишәрлеге алучылар артса, быел торак йорт алучылар күбәйгән. Шәһәр читендәге күчемсез милеккә, элеккечә үк, ихтыяҗ зур икән. Башка төрле күчемсез милеккә дә ипотека буенча алыш-бирешләр саны ишәйгән. Мәсәлән, фатир буенча ипотека саны – 17 процентка, торак булмаган биналар буенча – 18, машина өчен урыннар буенча 37 процентка арткан.

Гомумән, гыйнвар аенда барлыгы 7,3 меңнән күбрәк ипотека килешүе теркәлгән. Бу – алдагы елдагыга карагандa 12 процентка зуррак сан. Лилия Борһанова билгеләп үткәнчә, ташламалы кредитлау программасына халык арасында ихтыяҗ, элеккечә үк, бик зур. Росреестр гыйнвар аенда 500дән артыграк ташламалы ипотеканы теркәгән.

Вазгыять

QR-кодсыз тормыш

Дүшәмбедән искечә яңа тормыш башланды. Татарстанда QR-код системасы бетерелде. COVID-19га каршы тору чарасы буларак республикада QR-код куллану узган елның 11 октябреннән башланган иде. 22 ноябрьдән җәмәгать транспортында да код сорый башладылар.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Хөкүмәт йортындагы «шимбә киңәшмәсе»ндә кайбер чикләүләрнең гамәлдән чыгарылуы хакында Татарстан Президенты үзе хәбәр итте. Моңа коронавируска каршы күмәк иммунитетның формалашуы йогынты ясавын әйтте. Билгеле булганча, хәзер ул 80 процентка җиткән.

Шулай итеп, 21 февральдән түбәндәге очракларда QR-код күрсәтү таләп ителмәячәк:

- җәмәгать транспортында;
- боулинг, компьютер клубында;
- сәүдә үзәкләрендә;
- кафе-ресторан, театр, кинотеатр, концерт залы, спорт чаралары, цирк (тамашачылар саны 70 проценттан артмаска тиеш);
- балаларга сәүдә үзәкләренә ата-аналардан башка йөрү рөхсәт ителә;
- 23.00 сәгатьтән алып иртәнге алтыга кадәр мунча һәм сауна эше рөхсәт ителә.

Моңа өстәп ваклап сату нокталарына төнлә эшләү рөхсәт ителде.

Код күрсәтмәү ул әле гадәти саклану кагыйдәләрен үтәмәскә рөхсәт дигән сүз түгел. Рөстәм Миңнеханов искәртүенчә, җәмәгать урыннарында һәм транспортта битлек кию һәм социаль дистанция саклау сорала. Вакцина ясатмаган яисә соңгы алты айда коронавирус белән чирләмәгән 60 яшьтән өлкәнрәкләр өчен исә үзизоляция кагыйдәләре саклана. Шулай ук кальян тарту, җәмәгать туклануы нокталарына төнлә хезмәт күрсәтү тыела.

– Коронавирус инфекциясенә каршы вакцина ясату эшен дәвам итәргә кирәк. Шул ук вакытта кабат вакцина ясату юнәлешендә дә, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Хезмәт урыннарында, мәктәп, югары уку йортларында санитар кагыйдәләрне төгәл үтәргә кирәк. Аларның нәтиҗәле булуын күрәбез.

Президент Татарстан халкына киеренке вакытта аңлы булулары өчен рәхмәтен дә әйтте.

– QR-код системасына бәйле кертелгән чаралар мәҗбүри иде. Әмма без моның исәбенә күмәк иммунитет булдырдык, бу инде чикләүләрне киметергә мөмкинлек бирде, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Сүз уңаеннан, 21 февральдән, Россия Сәламәтлек саклау министрлыгы боерыгы буенча, коронавируска антитәнчекләре булган кешеләргә дә QR-кодлы белешмә бирелә башлады.

САН

Татарстанда 2454124 кеше вакцина ясаткан. Шуларның 1915680е икенче дозасын алган. Кабат вакцина ясатучылар саны – 236336 кеше.

Сүзгә-сүз

Владимир ПУТИН, Россия Президенты:

Бу территорияләрдә яшәүче кешеләр мыскыл ителде. Бертуктаусыз атышлар, блокада. Белгәнегезчә, алгы сызыкка якын урыннарда яшәүче кешеләр, гомумән, балалары белән подвалда яшәргә мәҗбүр булды.

(Донбасс һәм Луганскида яшәүчеләр турында әйткән фикере)

Теманың дәвамы 2 нче биттә >

ТАТАРСТАНДА – ТОРАК ТӨЗЕЛЕШЕ

Татарстанда гыйнвар аенда 397,5 мең кв.м торак кулланылышка тапшырылган. Бу – 4656 фатир һәм 1348 шәхси йорт.

РОССИЯ ТӨБӘКЛӘРЕНДӘ КҮПМЕ ТОРАК КУЛЛАНЫЛЫШКА ТАПШЫРЫЛГАН?



Транспортчыларга акча биреләчәк

Җәмәгать транспортында QR-кодлар кертелүгә бәйле зыянны каплау өчен, транспорт оешмаларына ноябрь һәм декабрь айлары өчен акча тәгаенләнгән. Аларга барлыгы 85,5 миллион сум күчереләчәк. Бу хакта Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының матбугат хезмәте хәбәр итә.

Хәзерге вакытта министрлык муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары белән транспорт оешмаларына акча бирү турында килешүләр төзи. Ведомствода аңлатып үтелгәнчә, акча муниципалитетларның имзаланган килешүләр һәм заявкалар тапшыруына карап күчереләчәк. Бүгенгә министрлыкка 38 муниципалитетның 13еннән килешүләр алынган инде. Муниципаль берәмлекләр, акчаны, үз чиратында, транспорт оешмаларына бирәчәк.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

«КАРА» КӨННӘР

Үткән атна шомлы һәм дәһшәтле хәбәрләр белән тәмамланды. Донбасстагылар үзләренә Украинадан һөҗүм итәргә җыенулары, тыелган кораллардан атулары хакында белдереп, Россиянең көнбатыш чигендә хәл кискенләште. Киев, әлбәттә, барысын да кире кага, каршы якны провокация оештыруда гаепли.

Дөресен генә әйткәндә, бу төбәктә атышларның беркайчан да тынганы юк, әмма соңгы көннәрдә авыр артиллерия – эре калибрлы туплар хәрәкәткә килде дип гауга кубарылды. Соңгыларын куллану Минск килешүләре нигезендә тыелган. Мәскәү – Донецк – Луганск күчәрендә инде зур сугыш башланган кебек: 700 меңгә кадәр Донбасс качагын Россиягә күчерү планнары игълан ителде. Әлегә кечкенә генә мәйданда яшәүче халыкка бик зур бәла килә. Вәләкин фаҗига коронавирус пандемиясе кебек үк планета масштабына җәелү белән яный.

Сәяси шахмат тактасында фигуралар менә болайрак тезелгән: Россия – берьялгызы. Донбассны исәпкә алмыйбыз, билгеле, чөнки алар мөстәкыйль сәяси көч түгел. Мәскәүне яклаган Венесуэла бар, Төньяк Корея бар. Болары сәяси белдерүләр ясаудан ерак китә алмыйлар. Аркадаш булырга мөмкин бердәнбер көч – Кытай тышкы эшләр министры Ван И, Украинаның суверенитеты, территориаль бөтенлеге якланырга тиеш, дип белдерде, димәк, бик яхшы дигәндә, Пекин нейтралитет саклаячак. Вакыйгалар кайнарланган һәм кызган бер вакытта Мюнхен конференциясе үткәрелде, анда чыгыш ясарга трибунага чыккан Зеленскийны Көнбатыш делегацияләре аягүрә басып һәм алкышлап каршылады. Зур сугыш уты кабызылырга тиешле төбәктәге ОБСЕ күзәтүчеләре атышларда Киевны түгел, гыйсъянчыларны гаеплиләр. Россия өчен бик тискәре мәгълүмат фоны инде бу. Британия Премьеры Джонсон Россияне 1945 елдан соң Европадагы иң зур сугышны башлап җибәрүгә әзерләнүдә гаепли. Бер генә өметле хәбәр бар: Макрон белән Путин телефоннан сөйләштеләр, француз лидеры Байден белән Путинны күзгә-күз очраштырырга тели. Байден, Россия Украинага бәреп кермәсә, саммитка риза. Сугыш котылгысызлыгы бик нык үсә ләкин. Берничә көн элек кенә Белоруссиядән гаскәрләрне чыгарырга вәгъдә биргән Мәскәү, аларны калдырырга булды. Көнбатыш чыганаклары, Америка разведкасына таянып, Путин инде гаскәрләргә һөҗүм башларга әзерләнергә әмер бирде дигән мәгълүмат тараталар. Россиянең Вашингтондагы илчесе Донбассның Украина төбәге булуын Мәскәүдә тануларын әйтә, сугыш җиле көнчыгыштан түгел, Киевтан исә дигән ишарә ясарга тырыша. Кремль шулай ук сугыш теләмәвен һәм башламаячагын тәкрарлап тора. Әмма акка кара белән тегелгән дезинформация ике яктан та ташкын булып ага. Бүгенгенең капма-каршысы булган белдерүләр иртәгә үк яңгырарга мөмкин.

Россиядә

БЕЗДӘ ДӘ ХӘЛЛӘР КИЕРЕНКЕ

Россиянең эчке мәгълүмат кырында да көнбатыш чикләрдәге вазгыять төп урынны алып тора. «Российская газета»ның дүшәмбе санында бу темага унлап материал бирелгән. Океан артыннан каты санкцияләр белән яныйлар, сумның девальвациясен (очсызлануын), инфляцияне һәм икътисадның аяктан егылачагын вәгъдә итәләр. Безнең өчен зур яңалык түгел инде түгелен. Әле дүшәмбе биржаларында ишекләрдән йозакларны алып кына өлгерделәр: доллар һәм евроның сумга һөҗүме, акцияләрнең түбәнгә таба тәгәрәве турында хәбәрләр ишелеп килә инде.

Россия Президенты Владимир Путин 60 яшькә кадәрге гражданнарны хәрби җыен үтү өчен чакыру турында указ имзалады. Бу – ел саен эшләнелә торган гамәл гамәлен, әмма гомуми шом фонында күңел авыр кабул итә. Стратегик ракета гаскәрләренең атом коралы йөртергә яраклы ракеталар атып уйнавы да шундый ук тәэсир ясый. Россиядә психик тайпылышларны дәвалый торган препаратларга ихтыяҗ кискен үскән. Соңгы айда антидепрессантларны 2021 елның шул чоры белән чагыштырганда 43 процентка күбрәк сатып алганнар. Нейролептиклар куллану да бик нык көчәйгән. Югары психик нерв эшчәнлеген киметүче бу даруларны 35 процентка күбрәк сатып алганнар. Үткән елның бер аенда 516 мең тартма нейролептик сатылган булса, быелгы бер айда 698 мең заказ канәгатьләндерелгән.

Кешеләр әҗәткә батканнар, азык-төлек продуктларына яңа бәя күтәрелеше рәсми рәвештә игълан ителеп торыла, ковидка бәйле проблемалар да гомуми психозны көчәйтте… Сишәмбе көнне, 22 февральдә, Федерация Советы белән Дәүләт Думасы уртак утырышка җыела. ФС сайтында бу утырышның хәрби пенсионерларга пенсияне арттыру турындагы карарны раслау өчен җыелуы игълан ителсә дә, көн тәртибенә Донбасс мәсьәләсе дә куелыр дип көтелә. Утырыш зур белдерүләрдән башка гына үтеп китсә, барыбыз өчен дә яхшы булачак.

Ярым күңелле, ярым күңелсез хәбәрләр дә җитәрлек. Җитештерүчеләр бәяләр күтәрелешен үлчәүгә яшерә башлаган. Азык-төлекне берничә граммга киметеп төргәклиләр дә иске бәядән саталар. Элек 85 граммлы булган «Россия» шоколады – 82 граммга, 95 граммлык каһвә – 85 граммга, «Макфа» дип аталган макарон төргәге 450 грамм урынына 400 граммга калган, мәсәлән. Күрер күзгә сизелми, ә җитештерүчеләргә акмаса да тама. «Тиен сумны саклый» дигән рус әйтеме тормышка ашырыла ягъни. Хәзерге яшьләр тиеннең ни икәнен беләләрдерме? Бу соңгы яңалыкка елмаеп та карарга була торгандыр, бәлки. Нәрсә генә булмасын, авырлыклар барыбер артта калачак.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

«Унбер»дә кунакта

Бар игътибар – балаларның киңкырлы үсешенә. «Унбер» лицеенда укучыларның нияләр белән шөгыльләнгәннәрен Татарстан Президенты да күреп кайтты.

Мәгълүм булганча, лицей узган елның 1 сентябрендә «Арт Сити» торак комплексында ачылды. Уку йортында халыкара дәрәҗәдәге сыйфатлы белем бирелә. Хәзер биредә 949 укучы белем ала.

«Унбер» дүрт төрле юнәлеш (математика, химия-биология, лингвистика һәм гуманитар) буенча эшли. Лицей директоры Алмаз Хәмидуллин сүзләренчә, белем йортында идарә итүнең мәгълүмати системасы үсеш алган, махсус мобиль кушымта эшләтеп җибәрергә җыеналар. Аның ярдәмендә укучыларга өстәмә мәгълүмат алырга, ә укытучыларга һәм ата-аналарга тиз арада элемтә урнаштырырга мөмкин булачак.

Татарстан Президентына лицейда узган чаралар хакында сөйләделәр. Алар арасында татар теле укытучылары өчен семинарлар да бар. Аның кысасында мөгаллимнәр татар телен укыту тәҗрибәсе һәм аны өйрәнүдә яңа алымнар белән уртаклашты.

Очрашуда Рөстәм Миңнеханов белем бирү классларын, китапханә, актлар залы, бассейн һәм ашханә белән танышты, лицей укытучылары белән аралашты. Сүз уңаеннан, биредә хезмәт коллективы да көчле: алар арасында Россиянең төрле төбәкләре (Самара, Ульяновск, Санкт-Петербург, Чаллы, Түбән Кама) һәм чит илләрдән (АКШ, Колумбия, Казахстан) чакырылган тәҗрибәле укытучылар да бар. Аларның күбесе – илкүләм һәм халыкара олимпиада җиңүче-призерларының остазлары.

tatarstan.ru

Көн кадагында

ЯРДӘМ ЯНӘШӘ

Татарстан читтә калмаячак. Республика Хөкүмәтендә Донецк һәм Луганск өлкәләреннән эвакуацияләнгән кешеләрне вакытлыча урнаштыру буенча оператив штабның беренче утырышында кыен хәлдә калганнарга ярдәм итү чаралары турында сөйләштеләр.

Оператив штабны Татарстан Премьер-министрының беренче урынбасары Рөстәм Нигъмәтуллин җитәкли. Аның составында Гадәттән тыш хәлләр, Эчке эшләр, Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау, Транспорт һәм юл хуҗалыгы, Мәгариф һәм фән, Яшьләр эшләре министрлыклары вәкилләре дә бар.

Республика Донецк һәм Луганск өлкәләреннән эвакуацияләнергә мәҗбүр булган 1 мең кешене кабул итәргә әзер. Аларны «Санта», «Жемчужина», «Ливадия», «Васильевский» шифаханәләренә урнаштырачаклар.

Эвакуацияләнгән кешеләр Казанга килеп төшүгә, барысын да вакытлыча яшәү урыннарына озатачаклар. Аларны кайнар ризык белән тәэмин итәчәкләр. Ихтыяҗ туса, медицина ярдәме дә күрсәтеләчәк.

Бизнес вәкилләре дә булышырга әзер. Әйтик, Чаллының «КамАЗ» җәмгыяте эвакуацияләнергә мәҗбүр булганнарга торак белән булышачак. «Без республиканың зур предприятиеләре җитәкчеләренә мөрәҗәгать итәрбез, кулдан килгәнчә барысын да эшләрбез. Чит кешенең кайгысына битараф калганыбыз юк», – диде КамАЗның мәгълүмат сәясәте департаменты башлыгы Олег Афанасьев.

Кемнән – суыткыч, кемнән – ризык, депутатлардан – бер көнлек хезмәт хаклары. «Бердәм Россия» партиясенең Татарстандагы бүлекчәсе дә гуманитар ярдәм җыюны оештырып җибәргән. Аның башкарма комитет җитәкчесе Марат Сәмигуллин сүзләренчә, партиянең төбәк секретаре Фәрит Мөхәммәтшин исеменнән республиканың 20ләп оешма-предприятиесенә хат җибәрелгән. «Кемнән – суыткыч, кемнән – ризык, урын-җир, битлекләр сорыйбыз», – ди ул.

Партиянең Татарстандагы бүлекчәсе акчалата да булышачак. Матди ярдәм җыю өчен депутатларның бер көнлек хезмәт хакын тотарга тәкъдим ителде. Бу акчага кирәк-яраклар сатып алачаклар.

Битараф булмаган халык та эвакуацияләнергә мәҗбүр булган кешеләргә торак белән булыша ала. Моның өчен Россиядә махсус проект эшли башлады. Тулырак мәгълүмат белән dom.rt.com сайтында танышырга мөмкин.

НИ ӨЧЕН КАЗАНДА ЯШИСЕ КИЛӘ?

Казан шәһәре Думасының 12 нче утырышында башкала мэры Илсур Метшин чыгышын тыңлаганда ук яшәр өчен уңайлы шәһәр илдә бүтән юктыр кебек тоела башлады. Сессия утырышында катнашкан Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов та Казан халкы санының бер миллион да өч йөз меңнән артып китүен әйткәч, күңелдән генә: «Начар урынга халык агылмас», – дип уйлап куйдым.

Бүген пандемия афәтен телгә алмыйча, бер генә җыелыш та узмый. Без зәхмәтне кайбер җитешсезлекләрне аклау өчен дә искә алып үтәбез. Ә менә Илсур Метшин, зарлануларны читкә куеп, шәһәр икътисадының тотрыклы үсешкә юл тотуы турында сөйли башлады. Узган ел бюджетка физик затларга салым кереме генә дә 2020 ел белән чагыштырганда 27 процентка арткан икән. Бу керемнәр гомуми салым күләменең 46,6 процентын тәшкил итә. Димәк, Казан халкы эшсезлектән интекми дигән сүз. Узган ел тулаем шәһәр буенча төяп озатылган продукция күләме 579,3 млрд сум тәшкил иткән. Шәһәр предприятиеләре исә 476 млрд сумлык товар җитештергән. Бу узган ел белән чагыштырганда 31,8 процентка күбрәк. Теркәлгән эшсезләр саны дүрт тапкыр кимеп, бу өлкәдә күрсәткеч пандемиягә хәтле дәрәҗәгә җиткән.

Саннарны алдап «шыттырып» язып булмый, чөнки үзең чәчкәнне барыбер үзең урасы була. Ел нәтиҗәләре буенча кече һәм урта предприятиеләр санының – 3,8 меңгә, ә үзмәшгульләрнең 36,2 меңнән 58 меңгә җитүе дә күктән алынган сан түгелдер дип уйлыйбыз. Саннар китерүне бераз туктатып торыйк. Артык баллы ризык тиз туйдыра бит ул. Узган елга хисап тотканда уңышлар турында күбрәк сөйләү һәм залдагыларның еш кул чабулары да, Президент ягына борылып, әледән-әле рәхмәт әйтүләр дә бераз сәеррәк тоела, күңелгә: «Бездә барысы да ал да гөл микәнни?» – дигән уйлар да кергәли башлаган иде. Ярый әле шәһәр башлыгы хәл итәсе мәсьәләләрне читләтеп узмады. Татарга хас хәйләкәрлек, зирәклек тә бар иде Илсур әфәндедә. Үзең башкарган эшләр турында матурлап сөйли дә белмәсәң, Президенттан ярдәм сорау да кыенрак булачак бит. Хәер, мэрия, шәһәр Думасы эшчәнлеген Рөстәм Нургали улы биш бармагы кебек белә, чөнки шәһәргә кагылган бөтен мәсьәләләрне хәл итүдә турыдан-туры катнаша ул. Мэрның яхшы мәгънәдә тагын бер «хәйләкәрлеге» шунда: кайбер мәсьәләләрне башкалар авызыннан да әйттерә. Бу утырышка Константиновка бистәсеннән территориаль иҗтимагый үзидарә рәисе Равил Муллаәхмәтов чакырылган булган. Сүз уңаеннан әйтик әле: Туган тел көнендә узган утырышта матур итеп саф татарча чыгыш ясаучы бердәнбер кеше иде ул. Менә шул егет: «Без – авылныкымы, шәһәрнекеме?» дигән сорау куйды да, – шәһәр кешеләре кебек үк салым да түлибез», – дип, кайбер зарларын сөйләп алды. Ягъни бистәдә мәктәп, балалар бакчалары җитешми, юлларны, ишегалларын үзләре карап тотарга азапланалар, юлларга асфальт җәясе иде… Кыскасы, бистәне төзекләндерү, социаль объектлар төзү өчен аларга аерым программа кирәк. Ә болай, халык җитәкчелеккә рәхмәтле икән.

Президент аның сөйләгәннәрен күңеленә салып куйды кебек. Юкса бистәләрдә проблемаларның һаман туа торуын һәм аларны чишү кирәклеген әйтмәс иде.

Утырышта блогер Булат Закировның чыгышын да бик кызыксынып тыңладылар. Ул халыкта фикер тудыруда нәкъ менә блогерларның өлеше зур булуын сөйләде. Чөнки алар халыкка якынрак, кеше зур җитәкчеләрнең сүзенә караганда аларга күбрәк ышана. Социаль челтәрләрдә җитәкчеләр блогер буларак ачылып китеп сөйләсеннәр иде. Һич югы блогерлар аша үз сүзләрен халыкка җиткерсеннәр иде, дигән фикердә ул. Аның уенча, рәсми сайтларда ихласлык җитми.

Аңа барысы да ихластан шаулатып кул чаптылар. Ә Президент: «Булат, моңарчы кайда йөрдең син? Элегрәк танышкан булсак, бергәләп күпме эшләр башкарган булыр идек», – дигәнрәк сүзләр әйтте. Бу шаярту түгел иде дип уйлыйбыз. Җитәкченең халыкка якынаерга тиешлеге турында сүзләр инде күптән йөри, ике арада упкынның шактый тирән булуын кайбер җитәкчеләребез үзләре дә турыдан-туры әйтә. Булат Закировның сөйләгәннәре шуларга бер куәт булыр да, «әйдә, халыкка хезмәткә!» дигән сүзләр тагын күңелләргә кермәсме дигән өмет бар. Халыктан Президент Аппаратына да меңәрләгән мөрәҗәгать керә икән.

Президент әйтүенчә, хәерчелек, реаль керемнәрнең аз булуы – җитәкчелек эшчәнлегенә бәя. 314 предприятиедә хезмәт хакы минималь хезмәт хакы күләменнән дә азрак икән.

Гомумән алганда, Илсур Метшин, аның командасы һәм Казан Думасы депутатлары эшчәнлегенә Президент югары бәя бирде. Утырышта әйтелгән, мөрәҗәгатьләрдә язылган проблемаларны, һәрвакыттагыча, бергәләп хәл итәчәкләр.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Илдар Мөхәммәтҗанов

БӘЛА – БАШ ӨСТЕНДӘ

Кышның куркыныч чагы җитте. Аяк астыннан бигрәк, өскә карап йөрергә туры килә торган вакыт. Кояш җылысы түбәләрдәге карны эретеп, боз сөңгеләре ясый башлады. Йорт түбәләрендәге карның да тик кенә ятасы килми: шуып төшәргә генә тора.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Әле шушы көннәрдә генә Лаеш районының Комлы Кавал авылында чак кына фаҗига булмый кала. Ишегалдында ике баласы белән уйнап йөргән ана, тавыш ишетеп, өскә карый. Ул түбәдән шуып төшүче кар өемен күреп, балаларын алып, читкә китеп өлгерә. Интернетта таралган видеодан күренгәнчә, кар шактый күп ишелеп төшә. Аның астында калган очракта, бәхетсезлек килеп чыгу ихтималы зур була. Бу вакыйга буенча тикшерү эшләре башланган.

Шуңа охшаш хәл Казанда да килеп чыга. Тик бу юлы автомобильгә зыян килә. Башкаланың Профессор Камай урамындагы торак йорт янында торган автомобиль өстенә зур боз кисәге төшә. Фотолардан күренгәнчә, бозлы кар автомобильнең алгы пыяласын ваткан.

Кызганыч, кышның язга авышкан көннәрендә мондый очраклар турында шактый ишетергә туры килә. Шуңа күрә тагын да игътибарлырак булып, өсне-асны карап йөрергә киңәш итә белгечләр. Балалар белән уйнар өчен йорт янын түгел, ә ачык мәйданчыкларны сайлау күпкә куркынычсызрак булыр, ди алар. Хәзер түбәләрне чистартканда яки кыекларында зур боз сөңгеләре булган йорт яннарын кызыллы-аклы тасма белән әйләндереп алалар. Аларга да мөмкин булганча игътибарлы булсак иде.

– Узган ел ишегалдында калдырган машинабызга түбәдән кар ишелеп төшкән иде. Бик зур зыян килмәсә дә, автомобильне ремонтка алып керергә туры килде. Әле ярый, идарәче компания үз гаебен таныды. Ремонтны алар хисабыннан ясаттык, – ди Биектауда яшәүче Илдар Кәлимуллин. – Күрше йортта яшәүче танышыбызның хәле тагын да яманрак булды. Баласы белән урамнан барганда, өстенә боз кисәге төшеп, кулын авырттырган иде.

Казандагы «Уңайлы йорт» идарәче компаниясе хезмәткәре Гөлнара Әдиятуллина әйтүенчә, йортларның авыш түбәләрендәге кар һәм боз сөңгеләрен чистарту – идарәче компанияләрнең бурычы. Күпкатлы йорт түбәләре һәм чарлаклар гомуми милек булып санала, һәм компания аларны карап торырга тиеш. Ә менә фатир балконы түбәсендәге кар, боз сөңгеләре өчен шушында яшәүчеләр җаваплы. Үзе чистарта алмаган очракта, милекче идарәче компаниягә язма рәвештә хат юлларга тиеш.

– Балкон өчен җаваплылык йорт хуҗасында булуга карамастан, балкондагы боз сөңгеләрен идарәче компания эшчеләре яки алар яллаган подрядчы оешма чистартырга тиеш, – дип искәртә белгеч. – Әгәр милекче компаниягә бу эшне башкарырга кирәклеге турында мөрәҗәгать итмәсә, түбәдән төшкән кар яки боз кешенең сәламәтлегенә яки милеккә зыян китергән очракта, фатир хуҗасы җаваплылыкка тартылырга мөмкин. Әгәр кеше яки милек җитди зыян күрсә, гаепләнүче кеше чыгымнарны үзе күтәрергә тиеш булачак. Фаҗига була калса, җинаять җаваплылыгына да тартылырга мөмкин.

Зөһрә САДЫЙКОВА

КАЛӘМ ХАКЫ

ХАЛЫКАРА ТУГАН ТЕЛ КӨНЕНДӘ ӘДӘБИ БӘЙГЕГӘ НӘТИҖӘЛӘР ЯСАЛДЫ

«Татар-информ»

Бәйге җиңүчеләре арасында хезмәттәшебез Марат Кәбиров та бар. Ул «Повесть» номинациясендә – икенче, «Поэма» номинациясендә өченче урын алды.

ҖИҢҮЧЕЛӘР

«Шигърият»
I урын – Лилия Гыйбадуллина;
II урын – Лилия Гыйбадуллина;
III урын – Фәрсия Зиннурова.
«Поэма»
I урын – Лилия Гыйбадуллина;
II урын – Рафис Корбан;
III урын – Марат Кәбиров.
«Хикәя»
I урын – Рүзәл Мөхәммәтшин;
II урын – Ләйсән Низамова;
III урын – Илсөяр Иксанова.
«Повесть»
I урын – Наилә Харисова;
II урын – Марат Кәбиров;
III урын – Хәбир Ибраһим.
«Шигырь» (үсмерләр әдәбияты)
I урын – Хәбир Ибраһим;
II урын – Йолдыз Шәрәпова;
III урын – Гөлүсә Батталова.
«Хикәя» (үсмерләр әдәбияты)
I урын – Гүзәл Әдһәм;
II урын – Гүзәл Әдһәм;
III урын – Ләйсән Абдрахманова.
«Повесть» (үсмерләр әдәбияты)
I урын – Лилия Гыйбадуллина;
II урын – Алмаз Гыймадиев;
III урын – Илдус Диндаров.
«Шигырь» (балалар әдәбияты)
I урын – Әнвәр Шәрипов;
II урын – Лилия Фәттахова;
III урын – Гөлназ Гафарова.
«Хикәя» (балалар әдәбияты)
I урын – Лилия Фәттахова;
II урын – Булат Ибраһим;
III урын – Фатыйма Гыйльметдинова.
«Роман»
I урын – Зөлфәт Хәким;
II урын – Фирдүс Гыймалтдинов;
III урын–Равил Сабыр.

Саллы әсәрләргә – саллы бүләкләр. Бәйрәм көнне Язучылар берлегендә Татарстан Президенты каршындагы татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәмендә үткәрелгән әдәби конкурста җиңүчеләрне бүләкләделәр. Бәйгедә җиңүчеләрнең кайсылары аеруча сөенә? Бер авторның берничә номинациядә җиңүе кемне уйга калдырган?

Әлеге бәйге турында инде бер генә язмадык. Язучылар арасында да, укучыларда да кызыксыну уятты ул. Акчалата призның гомуми күләме – 3 миллион 895 мең сум. Бу – беренче сәбәптер. Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиев әйткән сүзләр урынлы булыр монда. «Мул уңыш җыеп алу өчен, игътибар һәм акча «яңгыр»ы кирәк, әдәбиятчылар өчен икесе дә әһәмиятле», – диде ул. Икенчедән, бәйгегә юлланган әсәрләрнең авторлары бәяләүчеләр өчен ахыргача сер булып калды. Әдәби үзәктән читтә иҗат итүчеләргә бусы аеруча мөһим булган.

Барысын да уздырды

Җиңүчеләрне Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Президенты каршындагы татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов бүләкләде.

– Бәйгедә җиңүчеләрне бүләкләү тантанасының нәкъ менә Халыкара туган тел көнендә уздырылуы очраклы түгел. Сез иҗат иткәндә, телебез дә яшәячәк. Комиссия оешканнан соң, «Туган телебезгә мөнәсәбәтне ничек үзгәртергә?», «Бушлыкны ничек тутырырга?» кебек сорауларга җавап табу өчен шактый уйланырга туры килде. Әлеге бәйге Язучылар берлегенең мөмкинлекләрен дә эшкә җигәргә кирәк дигән фикер нәтиҗәсендә уйлап табылды. Җиңә алмаганнар бер дә борчылмасын иде. Җиңүчеләр исемлеген күргәч, бер үк кешенең берничә номинациядә иң лаеклы дип табылуы кечкенә генә шик тудырды. Әмма бәхәсләшер өчен әйтмим монысын. Нәтиҗәләргә килгәндә, курыкмыйча, бу бәйге барып чыкты, дип әйтә алам. 29 язма килеп, 30 җиңүче булса, аянычлы булыр иде. Шушының кадәр әсәр кабул иткәнбез икән, бу бит безнең милләтнең рухи яктан нинди дәрәҗәдә бай булуын күрсәтә. Димәк, без һичшиксез бу бәйгене дәвам иттерергә тиеш. Һәм бүген мин сезгә моны вәгъдә итәм, – диде ул.

Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла сүзләренчә, бәйге ачышларга шактый бай булган.

– Бүген, чын мәгънәсендә, зур бәйрәм. Әлеге бәйге татар әдәбияты тарихында зур вакыйга булып истә калачак. Билгеле, моңа кадәр дә әдәби конкурслар булып торды, ләкин монысы масштабы белән барысын да уздырды. Нәтиҗәдә без 1470 эш кабул иттек. Бу сан исә безнең язучыларның һәм, гомумән, татар әдәбиятының потенциалы турында сөйли, – диде ул. – Бәйгенең географиясенә тукталсак, әсәрләрне асылда Татарстан һәм Башкортстанда яшәүче авторлар юлласа да, якын-тирәдәге татарлар күпләп яши торган төбәкләр дә читтә калмады. Димәк, анда да татар рухы сүнмәгән. Әсәрләргә килгәндә, шаккатыручылар аз булмады. Әйтик, берничә номинациядә җиңгән Лилия Гыйбадуллина, шәп шигырьне ир-ат шагыйрьләр генә яза ала, дигән тезисны сызып ташлады. Ә «Повесть» номинациясендә җиңү яулаган автор олпат язучыларны да уздырды.

Ркаил Зәйдулла милли мәгариф мәсьәләсенә дә тукталды: «Милли мәгарифебез яшәсә, милли әдәбиятыбыз да озын гомерле булыр. Турыдан-туры бәйләнештә булган әлеге ике өлкәнең икесен дә игътибар үзәгендә тотарга кирәк», – диде ул үз чыгышында.

«Яшибез әле...»

Проза әсәрләрен бәяләгән жюри әгъзасы, филология фәннәре докторы Әлфәт Закирҗанов исә җиңгән әсәрләрнең татар дөньясын танытуга хезмәт итәчәгенә өметләнүен белдерде:

– Игътибар иткәнсездер, бәйгегә килгән әсәрләрнең саны шактый саллы. Ә сан белән сыйфат бер-берсенә тыгыз бәйләнгән, шуңа да бу бәйгедән соң күңелдә өмет хисе ныгыды. Призлы урыннарны яулаган әсәрләребез киң укучыга килеп ирешкәннән соң да уңай бәя алыр дигән өметтә калам. Алай гына да түгел, бу әсәрләр, башка телләргә дә тәрҗемә ителеп, татарны дөнья аренасында да танытуга хезмәт итәрләр дип уйлыйм. Билгеле, әдәби әсәрләрне укыганда мин аларның татар язмышы, социаль, милли, әхлакый проблемаларга багышлануына игътибар итәргә тырыштым. Көнкүреш вакыйгалары белән генә чикләнеп калмыйча, укучыны тормыш фәлсәфәсе турында уйланырга мәҗбүр итә алырдай әсәрләрнең җиңеп чыгуы төп максатларның берсе иде, – дип сөйләде ул.

«Шигърият» номинациясендәге әсәрләрне бәяләгән жюри әгъзасы, Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиев: «Бәйгегә килгән шигъри әсәрләрне бәяләргә нигә ризалаштым икән, дидем башта. Шыплап тулган ике тартма әсәр иде бит ул, көчкә күтәреп кайттым. 600дән артык әсәр! Башта авыр тоелса да, укыган саен сөендем. Әдәбиятка, сәнгатькә, туган телебезгә гашыйк кешеләр шулкадәр күп икән, димәк, киләчәгебез дә өметле. Монда иң оста, мәшһүр шагыйрьләр белән балалар да көч сынашты. Башта аптыраштa калсам да, соңыннан бу шартның да үзенә күрә бер әһәмияте, яшьләр өчен файдасы булуын аңладым», – диде, кичерешләре белән уртаклашып.

Балалар һәм үсмерләр өчен атап язылган әсәрләр арасында да лаеклылар табылган. Гәрчә монда активлык дәрәҗәсе башка номинацияләргә караганда түбән булса да.

– Бәйгегә килгән эшләр уйланырга мәҗбүр итте. Балалар әдәбиятында төп герой кем? Аның теле, өслүбе нинди булырга тиеш? Татар халкының, туган телебезнең үзенчәлекләрен балаларга ничек сендерергә? Сораулар күп, билгеле. Шуңа да мондый конкурслар дәвамлы булсын иде, – диде үсмерләр һәм балалар әдәбияты әсәрләренә бәя биргән жюри әгъзасы Вакыйф Нуриев.

Җиңүчеләр ни уйлый?

Әйткәнебезчә, бәйгедә катнашучыларның исемнәре жюри өчен ахыргача сер булып калды. «Повесть» номинациясендә җиңгән, Әгерҗедә яшәп иҗат итүче Наилә Харисова бәйгенең бу шартын үзе кебек язучылар өчен яхшы мөмкинлек дип атады.

– Әсәремнең язу вакыты очраклы рәвештә бәйге тәмамланып килгән вакытка туры килде. Нишләп әле үземне сынап карамаска, дидем дә, юлладым. Олпат язучылар катнашуын белсәм дә, күңел почмагында, җиңәрмен, дигән өмет яшәде. Ләкин минем өчен «шорт-лист»ка эләгү җиңүдән дә мөһимрәк иде. Казаннан читтә яшәүчеләр үз иҗатларына карата чын тәнкыйтьчеләрнең, әдәбият белгечләренең фикерләренә бик мохтаҗ. Язарга кирәкме, ташларгамы? Бу бәйгедә катнашу шушы сорауларга җавап эзләүгә дә бәйле, – диде ул.

Бәйгедә призлы урын яулаган иң яшь катнашучы белән дә сөйләштек. Кайбыч районының Борындык авылы кызы Ләйсән Абдрахмановага – 17 яшь. Ул, бәйгегә шактый үзенчәлекле хикәя җибәреп, өченче урынны яулаган.

– Бу бәйгегә инглиз цитатасы белән башланучы һәм тәмамланучы хикәя җибәрдем. Дуслык һәм мәхәббәт хисләре турында ул. Җиңә алуыма ышанып бетә алмыйм. Нинди генә бәйге булса да, яшь язучы өчен бик әһәмиятле ул. Җиңсәң дә, җиңелсәң дә, канатланып кайтып китәсең. Бүген исә сәхнәгә менгәндә шундый курыктым. Үзем куркам, үзем горурланам. Һәм, әлбәттә, соңгы булмасын дигән теләктә калам, – дип сөйләде ул безгә.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Актив иҗтимагый эшчәнлекләре, республикада ветераннар хәрәкәтен үстерүгә өлеш кертүләре һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының ветераннар (пенсионерлар) иҗтимагый оешмасы Советы рәисе **Иванов** Валентин Константинович; Татарстан Республикасы ветераннар (пенсионерлар) иҗтимагый оешмасының Зәй районы һәм Зәй шәһәре ветераннар (пенсионерлар) иҗтимагый оешмасы рәисе **Хәлиуллин** Геннадий Сәмигулла улы; Ватанны саклау эшенә һәм яшь буынга хәрби-патриотик тәрбия бирүгә зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы Чаллы шәһәренең Үзәк һәм Автозавод районнары хәрби комиссары **Ильясов** Рәшит Флүр улы; ветераннар хәрәкәтен үстерүгә, яшь буынга патриотик тәрбия бирүгә зур өлеш кертүләре, актив иҗтимагый эшчәнлекләре өчен «Әфганстан ветераннарының Россия берлеге» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан республика оешмасы идарәсе әгъзасы **Кабыш** Евгений Григорьевич; «Сугыш инвалидлары» – Әфганстандагы сугыш инвалидлары һәм сугыш җәрәхәтләре алган инвалидлар гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк оешмасы идарәсе әгъзасы **Кукаркин** Альберт Сәлим улы; республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Август-Кама Тамагы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең йөк автомобиле йөртүчесе **Хуҗин** Илфат Исмәгыйль улы; физик культураны һәм спортны үстерүдәге казанышлары, республикада волейболны популярлаштыруга зур өлеш кертүе өчен «Динамо-Казан» хатын-кызлар волейбол клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы командасы башлыгы **Лебедев** Андрей Александрович Татарстан Республикасының **«Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты бүлеге (мобилизация ресурсларын планлаштыру, билгеләү, әзерләү һәм исәпкә алу) бүлекчәсе башлыгы **Биктимеров** Илдар Илдус улы; Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен Россия Федерациясе Оборона министрлыгының «Казан Кызыл байраклы Жуков орденлы югары танк командa училищесы» федераль дәүләт казна югары хәрби белем бирү мәгариф учреждениесе музее мөдире **Гыймалетдинов** Альберт Миңнегаяз улы; хезмәт ветераны **Слипченко** Александр Сергеевич, Россия Федерациясе Оборона министрлыгының «Казан Кызыл байраклы Жуков орденлы югары танк команда училищесы» федераль дәүләт казна югары хәрби белем бирү мәгариф учреждениесенең тактика кафедрасы уку-укыту лабораториясе инженеры **Тульчанский** Игорь Юрьевич «**Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

Республиканың нефть сәнәгатен үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен нефть сәнәгате ветераны **Верия** Александр Иванович **«Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының «Олимп» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тренеры **Петров** Олег Ивановичка, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының «Юбилейный» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең йөзү буенча тренеры **Сафиуллин** Әлфир Гыйздулла улына, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «1 номерлы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тренеры **Тудияров** Андрей Витальевичка, «Стендка ату һәм ядрә белән ату буенча олимпия резервы республика спорт мәктәбе» дәүләт бюджет учреждениесе филиалы тренеры **Филиппов** Виктор Ивановичка, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «2 номерлы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тренеры **Шәрипов** Ринат Роберт улына, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «2 номерлы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тренеры **Щербаков** Виктор Алексеевичка **«Татарстан Республикасының атказанган физик культура хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

Белдерү

КАЗАН «ОРГСИНТЕЗ» ПРЕДПРИЯТИЕ АКЦИОНЕРЛАРЫНЫҢ АНКЕТА МӘГЪЛҮМАТЛАРЫН ЯҢАРТА

Казан «Оргсинтез» гавами акционерлык җәмгыяте һәм акционерларының төп реестрын алып баручы «Евроазиатский регистратор» компаниясе 2022 елның 1 февраленнән Казан «Оргсинтез» гавами акционерлык җәмгыяте реестрында акционерларның анкета мәгълүматларын бушлай яңарту программасының башланып китүе турында хәбәр итә.

1992 елда предприятиедә хосусыйлаштыру башланды. Акцияләрнең бер өлеше хезмәт коллективына милеккә тапшырылды. Россия законнары нигезендә, акционерларга үзләренең мәгълүматлары үзгәрү турында реестр тотучыга вакытында җиткерү бурычы йөкләнгән. Кыйммәтле кәгазьләр әйләнешен тәэмин итү һәм акционерларның дивидендларны үз вакытында алуы өчен кирәк бу.

Хәзерге вакытта реестрда 1,5 меңгә якын акционер исәпләнелә. Алар турында мәгълүматлар искергән. Шуңа күрә кайберләре еллар буе хатлар һәм дивидендлар алмыйча килә.

Программаның гамәлдә булу вакыты – 2022 елның 1 февраленнән 31 мартка кадәр. Бу чорда акционерлар үзләренең анкеталарына үзгәрешләрне бушлай кертә ала. Моның өчен «Евроазиатский регистратор» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Адресы: Казан шәһәре, Зинин урамы, 10а йорт; Түбән Кама шәһәре, Корабельная урамы, 1 йорт.

Белешмәләр алу, шулай ук коронавирус инфекциясе таралмауга юнәлдерелгән чараларны үтәү максатыннан, түбәндәге телефоннар аша алдан язылып куярга киңәш итәбез: Казан шәһәрендә (843) 207-17-70, Түбән Кама шәһәрендә (8555) 39-94-70, 39-94-20.

КӨН ДӘ БЕР ТАТАР СҮЗЕ

И туган тел!

Иң бай сүзлек! «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»н тәкъдим итүгә багышланган матбугат очрашуында Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре әнә шулай диде. Әлеге алты томлык барлыгы 70 мең сүзне үз эченә алган.

Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге мөдире Ринат Сәфәров әйтүенчә, институттагы 11 бүлекнең өчесе тел юнәлешендә эш алып бара.

– Сүзлекләрнең бер ягы бар. Алар кичәге көнне чагылдыра, берникадәр вакыт узгач, искерә башлый. 30–40 елдан бары үз тарихын чагылдырган документка әйләнә. Шуңа күрә яңа сүзлекләр төзү ихтыяҗы туа. XXI гасырны алсак, институт барлыгы 50дән артык сүзлек төзегән. Алар арасында гадиләре дә, аңлатмалы сүзлекләр дә бар. 2021 елда алты томлык дөнья күрде. Бу эш 2000 нче еллар башында ук планлаштырылган иде. Галимнәр күп булса, болай озакка сузылмас та иде, бәлкем. Башта коллектив зур иде, хәзерге кебек 5–6 кеше генә түгел. Беренче том 2015 елда нәшер ителде, шуннан бирле һәр ел саен берәр томы басылды. 2021 елда исә соңгы томны кулга алдык, – дип сөйләде Ринат Сәфәров. – Татарстан китап нәшрияты белән килешү нигезендә хәзерге алты томлыкның икенче басмасын бастыра башладык. Икенче басма беренчесеннән сүзләр саны буенча баерак. Ул сатуда бар, районнардагы китапханәләргә таратылды. Сүзлекләр подвалда яту өчен, үзебез өчен генә бастырылмый, ул милләттәшләргә, эш коралы тел булган һәр һөнәр иясенә барып җитәргә тиеш. Моннан да тулырак сүзлек бар дип әйтә алмыйм. Аның электрон форматларын да эшлибез. Татарстан Фәннәр академиясе сайтыннан түләүсез кулланырга мөмкин.

Лексикология бүлегенең өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Илһамия Сабитова сүзлек төзү нечкәлекләре белән таныштырды.

– Сүзлек төзүчеләр – бик сирәк белгечләр. Ник дигәндә, аларны бер югары уку йорты да әзерләми, сүзлек төзергә махсус өйрәтми. Шуңа күрә филология белеме алган һәр кеше дә сүзлекче була ала дигән сүз түгел. Сүзлекче эшкә бик җаваплы карарга тиеш, чөнки ул сүзләрнең язылышының, кулланышының дөреслеген закон кебек билгели. Галимнәр кебек таләпчән дә булырга тиеш. Әйдә, ярар инде дип калдырып китәргә ярамый. Мәсәлән, бер сүзлек мәкаләсе эшләгәндә, бер сүзне алып, башта барлык татар сүзлекләренә, аннан казах, төрек, үзбәк һәм башкаларда ничек икән дип, төрки телләргә мөрәҗәгать итәбез, рус сүзлекләреннән карыйбыз. Һәрберсен ачыклаганнан соң гына сүзлек мәкаләсе барлыкка килә. Алай да хәл итә алмасак, барыбыз бергәләп киңәшләшәбез. Бик күп вакытны ала, озак төзелә. Бу алты томлыкны төзи башлаганда, проектта катнашабыз, диючеләр бик күп булды, тик эш тәртибе, таләпләр белән танышкач, авыр эш дип, баш тарттылар. Сүзлекчеләр һәрбер халыкта да юк. Бездә күп булмаса да, бар әле. Татар теле сүзлекләре бар, алар күп төрле. Файдаланырга гына кирәк. Без сүзлекләр белән кызыксыну җитеп бетми дип уйлыйбыз. Укытучылар, язучылар гадәт буенча файдаланалар. Бер теләк бар. Журналистлар сүзлекләрне ешрак ачып карасын иде. Сүзлекләр туплаганда, вакытлы матбугатка да игътибар итәбез. Андагы җитешсезлекне күреп, йөрәгебез әрни, – ди Илһамия Сабитова.

Лексикография бүлегенең өлкән фәнни хезмәткәре Фәридә Таһирова белдергәнчә, аңлатмалы сүзлек ул – милләтнең иң зур китабы. Анда сүз байлыгы иң киң дәрәҗәдә чагыла.

– Гадәттә, аңлатмалы сүзлек үз чорын чагылдыра. Алдагы сүзлекләрдән 40–50 ел вакыт узгач, телдә, җәмгыятьтә, фән, техника һәм башка тармактагы үзгәрешләр нindидер критик хәлгә җиткәч, аларны халыкның төп сүзлегендә чагылдыру ихтыяҗы туа һәм өр-яңа сүзлек төзелә. Өч томлык аңлатмалы сүзлек эшләнеше, дәрәҗәсе буенча төрки халыклар арасында иң беренче урында тора дип әйтә алыр идек. Кайбер халыклар арасында аны әле яңа гына төзи башлаучылар да бар. Удмурт, чуашларныкы басылып чыкты. Мондый җитди проектлар озак эшләнә. Максат – сүз саны түгел, хәзерге чордагы татарча гомумхалык телен чагылдыру, – диде Фәридә Таһирова.



Илдар Мөхәммәтҗанов

Журналистлар сүзлеккә «ковид», «коронавирус» кебек яңа сүзләрнең керү-кермәве белән кызыксынды.

– Россия Фәннәр академиясе тел белгечләре сүзләренә караганда, рус телендә көнгә ике сүз туа. Бәлкем, татар телендә алай ук түгелдер. Ярар, бер сүз туа дип әйтик. Елга 365 сүз яки сүзнең бер мәгънәсе туа икән, димәк, ул чыккан сүзлеккә теркәлми. Шуның өчен яңа сүзләрне кертүнең форматын уйлыйбыз. Монда кәгазь сүзлекләр булыша алмый. Википедия тибындагы электрон сүзлекләр төзи башлау проблемадан чыгу юлы кебек тоела. Ләкин бу эшне башлауга барып җиткән юк әле. «Коронавирус» бик күптәннән медицина телендә бар, «үзизоляция»не кертеп өлгерә алдык. «Үзмәшгуль», «үзмәшгульлек» сүзләре урын алды, – диде Ринат Сәфәров.

Сәрия МИФТАХОВА

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

«Татмелиорация» траст компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте коллективы, «Татмелиорация» траст компаниясе» ачык акционерлык җәмгыятенең элекке эксплуатация бүлеге башлыгы

Әсхәт Харис улы Әхмәтшинның

вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Спорт

Алтын бирмәделәр

Шау-шулы Олимпиада Татарстан спортчылары өчен иң уңышлысы булып чыкты. Пекинга республикадан 8 кеше барды, шулардан 5есе медальгә ия булды. Шатлану һәм горурлану гына түгел, нәтиҗә ясау өчен дә кирәк бу медальләр.

6 алтын, 12 көмеш һәм 14 бронза. Россия спортчыларының Пекин Олимпиадасындагы уңышы бу. Хәтта Сочида да азрак булган. СССР чорындагы иң зур күрсәткеч булып 1988 елда Калгари Олимпиадасындагы 29 медаль санала. Әлбәттә, медаль күбрәк булган саен күңелләрәк. Әйтик, хоккейчылардан алтын көткән идек. Әмма җиңү финнарга насыйп булды. Безнекеләр исә көмеш белән генә канәгатьләнде. Ә бит НХЛдагы түрәләр, үзләрендәге уенчыларны Олимпиадага җибәрмичә, Россия хоккеена менә дигән бүләк ясаган иде. Әмма бу мөмкинлектән файдалана алмадылар. КХЛ уенчыларыннан тупланган команда бер генә очрашуда да чемпионлыкка лаек уен күрсәтә алмады. Алексей Жамнов кулы астында чыгыш ясаган хоккейчылар һөҗүмгә барудан бигрәк, көндәшнең ялгышуын көтте. Ә көндәш ялгышмады. Швейцария белән Даниядән өстен чыгарга мөмкин әле. Чехларга исә оттырдык, шведларны буллит белән генә җиңә алдык, финалда финнар көчлерәк булып чыкты. Олимпиада алдыннан гына тренерлар алмаштырып уйнау, команда туплаганда аерым бер клубның мәнфәгатьләрен өстен кую нәтиҗәсе бу. Хоккей сөючеләр команданың икенче урын алуын уңышсызлык дип кабул итте. Алай түгел, киресенчә, сөенергә кирәк. Чөнки НХЛ уенчылары да кайтып кушылса, бу команда беренче өчлеккә дә кермәскә мөмкин иде. Аның каравы «Ак барс»тан капкачы Тимур Билалов белән һөҗүмче Дмитрий Воронков Кытайдан көмеш медальләр алып кайта. Моңа кадәр Казан командасы уенчыларының Олимпиадада медаль ота алганы юк иде.

Евгения Тарасованың да Пекинга сәфәре уңышлы булып чыкты. Казан кызы иптәше Владимир Морозов белән спорт парлары ярышында икенче урынны алды. Ул гына да түгел, беренче урындагы Кытай спортчыларыннан нибары 0,62 баллга калыштылар. Хәер, артыгын өмет итеп тә булмас иде. Кытайлар үзләрендә чыгыш ясаган һәм шуның аркасында хөкемдарлардан үзгә мөнәсәбәткә лаек булган өчен генә түгел. Россия спортчыларының фигуралы шууда дүрт алтынның өчесен алуы оештыручыларга да кызык түгел. Ә кызык ул – игътибар, реклама һәм акча дигән сүз. Хәтерләсәгез, Тарасова белән Морозов моннан 4 ел элек Пхенчхан Олимпиадасында да көмеш откан иде. Дөрес, команда ярышында. Бу юлы исә шәхси турнирда да осталыкларын расладылар.

tatarstan.ru

Лениногорск егете Данил Садриев та (рәсемдә) тарихка керде. Ник дигәндә, Россия спортчыларының трамплиннан сикерү ярышларында 54 ел дәвамында медаль ота алганы юк иде. Данил инде Татарстанга кайтып, якыннарын сөендерергә өлгерде. Иптәшләре белән команда ярышларында икенче урынны алган егетне якшәмбе көнне Казан аэропортында зурлап каршы алдылар. «Бу әле минем беренче генә медалем, шуңа күрә Олимпия призеры булуыма ышанып та бетә алмыйм. Казанга кайтып, мине ничек зурлап каршы алганнарын күргәч кенә ни эшләгәнебезне аңлый башладым», – диде Данил. Сөенеп утырырга вакыт күп булмаячак. Егет киләсе Олимпиадада шәхси ярышларда медаль яулау турында хыяллана. «Гомергә истә калырлык вакыйга булды бу. Дүрт елдан тагын медаль булсын өчен тырышып эшләячәкбез. Әлегә исә өйгә кайтып, әбием белән күрешәсем килә. Чөнки тагын ике көннән ярышларга китәргә кирәк. Соңгы ике елда бик сирәк кайтам. Шуңа күрә урамга да чыгып тормыйм», – диде ул. Данилдан уңыш сере турында сораштылар. «Лениногорск кебек кечкенә генә шәһәрдә үсеп, иң көчле спортчылар арасына керү өчен бик нык тырышырга, бу спортны яратырга кирәк. Ә трамплиннан сикерүне яратмый мөмкин түгел. Ул – артык техник, артык катлаулы спорт төре. Менә шуны аңлый алсаң, бик зур ләззәт кичерәсең», – ди көмеш медаль иясе.

Татарстан спортчысы булып саналган Вик Уайлдның сноубордчылар арасында параллель слалом ярышында откан бронза медаленә дә сөенергә мөмкин. Әмма медальләр шатлану һәм горурлану гына түгел, нәтиҗә ясау өчен дә кирәк. Әйтик, Лениногорскидан яңа чемпионнар үсеп чыксын өчен, андагы искергән трамплинның язмышы ничек булачак? Фигуралы шууда инде күп еллар дәвамында Евгения Тарасованың уңышына сөенәбез, Камилә Вәлиеваның боздагы тәүге адымнарын Казанда ясавын искә алырга яратабыз. Ә яңа кызлар пәйда булсын өчен, спортның бу төренә игътибар җитәрлекме? Сораулар аз түгел. Сөенгән арада аларга җавап та табасы бар.

ПЕКИНДА КЕМНӘР КҮПМЕ МЕДАЛЬ ОТТЫ?

№	Ил	1	2	3	Барлыгы
1	Норвегия	16	8	13	37
2	Германия	12	10	5	27
3	Кытай	9	4	2	15
4	АКШ	8	10	7	25
5	Швеция	8	5	5	18
6	Нидерланд	8	5	4	17
7	Австрия	7	7	4	18
8	Швейцария	7	2	5	14
9	**Россия**	**6**	**12**	**14**	**32**
10	Франция	5	7	2	14

ҮЛЕМ ҖИТЕШТЕРҮЧЕЛӘР

ФӘН УРЫНЫНА НАРКОТИКНЫ САЙЛАГАН ЕГЕТНЕҢ КИЛӘЧӘГЕ ТӨРМӘДӘ УЗАЧАК

Суд залыннан

Россия Эчке эшләр министрлыгыннан алынган мәгълүматларга караганда, 2021 елда илнең төрле төбәкләрендәге яшерен лабораторияләрдә заманча технологияләр кулланып, наркотикларның моңарчы билгеле булмаган 1654 яңа төре җитештерелүе ачыкланган.

pixabay.com

Төрле урау юллар белән чит илләрдән кертелә торган наркотик матдәләр генә җитмәгән. Аны хәзер идән асты лабораторияләрендә күпләп җитештерәләр. Белгечләр әйтүенчә, мондый юл белән әзерләнгәннәре аеруча куркыныч. Аны кулланудан меңнәрчә кешенең гомере өзелгән, гаиләләренә, якыннарына, туганнарына кара кайгы килгән.

Татарстан буенча эчке эшләр министры Артем Хохорин сүзләренә караганда, узган ел наркотиклар белән сату итүче 300дән артык оешкан төркем эшчәнлегенә карата җинаять эше судларда каралып, гаеплеләр тиешле җәзасын алган. Республикага наркотиклар кертү белән шөгыльләнүче 49 канал, 1314 сайт ябылган, 7 яшерен лаборатория эшчәнлеге туктатылган.

Шундыйларның берсе – Казан читендәге Сокуры бистәсендәге шәхси йортта яшерен лаборатория оештырып, зур күләмдә наркотик матдәләр җитештерүче Зиннәтулла Данилов та күптән түгел Лаеш районы суды карары буенча каты режимлы төрмәдә тоту шарты белән озак елларга ирегеннән мәхрүм ителде.

Явыз ниятле үрмәкүч сыман Россиянең җиде төбәгендә үз ятьмәсенә торган саен күбрәк корбаннар эләктерә алган «Зиновий бандасы»н оештыручы Зиннәтулла Данилов кем ул? Ничек итеп Татарстан башкаласы белән янәшәдә урнашкан тыныч кына бер авылда меңнәрчә кешене агулый алырлык күләмдә ясалма наркотиклар җитештереп яткан?

Журналист буларак хөкем ителүче турында кызыксынуымны белгәч, аның язмышы өчен борчылып, Лаеш районы судына килгән дистәгә якын кешенең һәркайсы йөзен читкә борып, тизрәк китү ягын карады. Сәбәпләре аңлашыла инде. Кемнең шундый явыз ниятле кешенең якыны буласы килсен?! Куркыныч наркотиклар кулланып, чәчәк кебек чагында гомерләре өзелгәннәрне яисә якыннарын кайгы-хәсрәткә кем этәрүен күпләр белми дә кала бит.

1990 елда Чиләбе шәһәрендә яшәүче Даниловлар гаиләсендә өченче бала булып дөньяга килгән Зиннәтулла мәктәптә укыганда үзен химия, биология фәннәреннән гаҗәеп сәләтле итеп таныта. Судта катнашучы, бүген башкаланың бер югары уку йортында эшләүче исемен күрсәтмәүне үтенгән бер абзый сүзләренә караганда, аның сабакташы химия буенча өлкә бәйгесендә катнашып, берничә тапкыр җиңүче була. Мәктәпне алтын медальгә тәмамлаган егеткә Мәскәү университетына укырга керү дә кыен булмый.

– Замана шаукымына ияреп, җиңел акчага кызыкмаган булса, аңардан танылган галим чыга алган булыр иде, – ди сабакташы.

Һәрхәлдә, алдагы берничә дистә ел гомерен төрмә куркынычы астына куеп, бүгенге кебек тимер рәшәткә артында мескен кыяфәттә утырмаган булыр иде.

– Университетны тәмамлагач, аспирантурада калды. Лабораториядә эшләде. Инде диссертация яза башлаган иде. Ишетүемчә, бер танышының үтенече буенча мефедрон һәм башка төр химикатлар кушып, наркотикка охшаш химик матдә ясарга алынган. Әйтәм ич, башы эшли аның. Гап-гади химикатлардан да әллә нәрсәләр ясый ала. Әмма кыңгыр эш кырык елдан соң да бер килеп чыга ул. Зиннәтулланы шуның аркасында эшеннән җибәрделәр. Аннары мин аның Чиләбедә, бер ара Краснодар шәһәрендә яшәве турында ишеттем. Казанга кайтып төпләнергә уйлавын да соңлап кына белдем, – ди судта катнашкан абзый.

Тик җитештергәнне сатасы да бар бит әле. Монда инде Чиләбе шәһәрендә бергә үскән танышлары ярдәмгә килә. Тикшерү материалларыннан күренгәнчә, ул бары тик наркотик матдәләр җитештерү белән шөгыльләнгән. Тарату-сату эшләре башкаларга калган.

Тагын шунысы гаҗәп: Россия Хөкүмәтенең махсус карары белән составына наркотик һәм психотроп матдәләр кергән химикатларны сату катгый тыелса да, наркотик матдәләр җитештерү өчен кирәк булган катнашмалар, әйтик, мефедрон, метилметкатинон кебек химикатларны интернет-сайтлар аша табып, интернет-кибетләр ярдәмендә кайтартуның бүген дә әллә ни кыенлыгы булмаган. Хәер, Чиләбедә яшәгәндә Зиннәтулла кирәкле химикатларны башка кеше исеменә кайтартса да, тикшерүчеләр аның кайчан һәм күпме химикатлар кайтартуын тиз ачыклый алган булыр иде.

Шуны сизептер, Зиннәтулла яшәү урынын берничә тапкыр алыштырган. Берничә ел Чиләбедә яшәсә, аннары Краснодар шәһәрендә кыңгыр эшләрен дәвам иткән. Узган ел исә Татарстанга кайтып, Лаеш районының Сокуры бистәсендә ике катлы йорт сатып алган. Наркотикларны идән астындагы яшерен лабораториядә берүзе җитештергән. Аны кемнәргә ничек таратуларын белми. Төркемдәшләре белән бары тик кәрәзле телефон аша гына аралашкан.

Тикшерү органнары тарафыннан аның гамәлләре буенча дүрт томлык материал тупланган булса да, суд барышында Зиннәтулла үзен яшерен рәвештә наркотиклар җитештерүче итеп түгел, ә җинаятьчел төркем корбаны итеп күрсәтергә тырышты. Янәсе, ул ниндидер фәнни ачыш ясамакчы булган. Ә наркотиклар җитештерергә аны куркытып, янап мәҗбүр иткәннәр.

Тик менә тикшерү материаллары гына киресен раслый. Наркотик матдәләрне тарату белән шөгыльләнүче төркем әгъзалары наркотик матдәләр җитештерү өчен күпләп кирәк булган натрий гидроксины, фенил, пирролидин, пентан яки метилэфедрон кебек химик матдәләрнең ни икәнен дә белми. Шулай булса да, аларның һәркайсы үзенә тиешле җәзаны алачак. Тикшерү материалларыннан күренгәнчә, әлеге җинаятьчел төркемдә төп җаваплы кеше Зиннәтулла Данилов үзе булуы көн кебек ачык.

Лаеш районы суды әлеге эшне карап тикшергәннән соң, Россия Федерациясе Җинаять Кодексының 228 маддәсе нигезендә Зиннәтулла Даниловны гаепле дип тапты һәм каты режимлы төрмәдә тоту шарты белән унбер елга ирегеннән мәхрүм итте.

Камил СӘГЪДӘТШИН

САКЛАУЧЫ ДА, ЯКЛАУЧЫ ДА СЕЗ!

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Гаиләдән башлана

Ватанны саклау элек-электән ир-егетнең изге бурычы санала. Дөрес, соңгы елларда бу төшенчәгә мөнәсәбәт шактый үзгәрде. «Левада» үзәге тарафыннан уздырылган соңгы сораштыру нәтиҗәләрен генә алыйк. Җавап бирүчеләрнең 16 проценты үзенең ватанпәрвәр түгеллеген әйткән. Тикшерүдә катнашучыларның күпчелеге исә (82 проценты) үз иле белән горурлануын, аны якларга, сакларга әзер булуын белдергән. Дөрес, соңгы арада көндәлек тормышыбыз да Ватанны саклауның ни дәрәҗәдә мөһим булуын раслап кына тора.

Татарстан Иҗтимагый палата әгъзасы, «Татарстан Республикасының күпбалалы гаиләләре» иҗтимагый төбәк оешмасы рәисе Артем Кузнецов Ватанны саклау төшенчәсенә карата мөнәсәбәт үзгәрүенең төп сәбәбен ватанпәрвәрлеккә игътибар кимүдә күрә.

– Безнең заманда һәр нәрсәнең нигезендә ватанпәрвәрлек ята иде. Хәзер моңа игътибар азайды. Бүген аның белән беркем шөгыльләнми диярлек. Кызганыч, безнең балаларны да, аларның дөньяга карашын да интернет тәрбияли, – ди Артем Кузнецов.

Безнең илнең төп дошманы дип демографиянең елдан-ел начарлануын, халык саны кимүне атый ул. Бүген илне нәкъ менә шушы афәттән сакларга кирәк дигән фикердә.

– Балага ватанпәрвәрлек хисе иң элек гаиләдә сеңдерелергә тиеш. Моның өчен эшне үзеңнән башларга кирәк. Ватанпәрвәрлек төшенчәсе хәрби хезмәт белән генә чикләнми бит. Үз илеңне ярату – аның халкын, традицияләрен, әйләнә-тирәне ярату дигән сүз. Балаларыңа әнә шуны күрсәтеп гомер итә алсаң, алар да сине кабатлап, шулай ук яшәячәкләр. Ватанпәрвәрлек хисен тәрбияләү өчен, илдәге социаль-икътисади вазгыятьне дә җайга салырга кирәк. Күреп торабыз: бәяләр арта, хезмәт хаклары үзгәрешсез кала. Соңгы унбиш ел эчендә торак бәяләре ун тапкыр артты. Ул вакыт эчендә беребезнең дә хезмәт хаклары ун тапкыр артмады бит. Киресенчә, илдә кредитын түли алмаучылар, банкротлыкка чыгучылар күбәйде. Бу мәсьәләне хәл иткәндә әнә шуларны да уйларга кирәк, – ди Артем Кузнецов.

«ВТ» архивыннан

Малай да еласын

Ир-егет – ил терәге, ди халык. Илнең генә түгел, тормышның тоткасы булырлык көчле зат нинди сыйфатларга ия булырга тиеш? Яклаучы, саклаучы, терәк булырдай чын ир-атны ничек тәрбияләргә? Психолог Чулпан Нигъмәтҗанова фикеренчә, ир баланы кечкенәдән җаваплылыкка өйрәтергә кирәк.

– Ул үз эше, гамәлләре өчен җаваплылык тоярга өйрәнсен. Үзенә нәрсә кирәген төгәл белсен. Шундый малайлар кыю, максатчан ирләр булып үсә дә инде. Баланың сәләтләрен вакытында күреп алып, аны үстерә белергә дә кирәк. Ир кешенең физик һәм рухи сәламәтлегенә физик активлыкның йогынты ясавын да онытмагыз, – ди белгеч.

Психолог ир бала тәрбияләгәндә замана ата-аналары ясаган иң төп хаталарны да искәртте. Шулар арасында иң киң таралганы – чамадан тыш кайгырту. «Күп кенә ата-ана баланың, бигрәк тә улларының чыр-чу килеп уйнауларыннан курка. Ә бит бала шул рәвешле дөньяны танып белә. Пычракны тотып, күлләвектә батып карап кына аларның нәрсә икәнен аңлый ала ул. Шуңа күрә мондый вак-төяк мәсьәләләрдә аңа ирек бирергә кирәк», – ди психолог.

Чулпан Нигъмәтҗанова малайларга кыю, максатчан, чын ир-ат булып формалашырга комачаулаган тагын бер тәрбия хатасын атый. Монысы балага: «Син – малай кеше, елама, түз», – дияргә яратучылар игътибарына. «Ир бала да – тере җан иясе. Ул да башкалар кебек ук борчыла, шатлана, ачулана, кирәк икән, елап та җибәрә ала. Аның хис-кичерешләренә киртә куймагыз. Киресенчә, ир баланы уй-кичерешләрен күрсәтергә өйрәтергә кирәк. Статистикага күз салсак, бик күп ирләр инфаркт, инсульттан үлә. Бу, нигездә, көчле затларның эмоцияләрен күрсәтә белмәү нәтиҗәсе», – ди психолог.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 7080 данә
Гомуми тираж – 17126 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 226

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты
(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).
16+